КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 3 апрель г.Казань № 221

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәне, муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алучыларны билгеләү советы составын, муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 ел, 25 ноябрь, 1131 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәне, муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алучыларны билгеләү советы составын, муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтүгә

Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын түләү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 ел, 25 ноябрь, 1131 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 1 март, 193 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

3.2 пунктның таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Номинацияләр исемлеге | Проектлар саны | Бер грант күләме, сум |
|---|---|---|
| Мәдәният-ял эшчәнлеге | 19 | 250 000,0 |
| Китапханә эше | 13 | 180 000,0 |
| Музей-күргәзмә эшчәнлеге һәм халык сәнгать кәсепләре | 5 | 250 000,0 |
| Театр һәм музыка сәнгате | 2 | 250 000,0 |
| Кинематография | 2 | 250 000,0 |
| Сәнгать-эстетика белеме бирү | 12 | 180 000,0»; |

3.11 пунктның икенче абзацында «10 көн» сүзләрен «14 көн» сүзләренә алмаштырырга;

3.17 пунктның беренче абзацында «биш көн» сүзләрен «14 көн» сүзләренә алмаштырырга;

3.18 пунктта «өч көн» сүзләрен «биш көн» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктта «20» санын «16» санына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алучыларны билгеләү советы составын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 25 ноябрь, 1131 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 3 апрель, 221 нче
карары редакциясендә)

Муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең
иҗади коллективлары проектларына ярдәм күрсәтү өчен
Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алучыларны билгеләү советы
составы

| | |
|---|---|
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры, совет рәисе |
| Әдһәмова Юлия Илдар кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары, совет рәистәше |
| Мифтахова Алсу Равил кызы | «Татарстан Республикасының Мәдәният өлкәсендә инновацияләрне кертү һәм традицияләрне саклап калу буенча ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, совет рәистәше урынбасары |
| Совет әгъзалары: | |
| Айтуганова Миләүшә Ләбиб кызы | «Татаркино» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры (эксперт) |
| Вәлиуллина Наилә Рәфикъ кызы | «Республика яшүсмерләр китапханәсе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры (эксперт) |
| Вяткина Алиса Львовна | «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе генераль директоры (эксперт) |
| Зыятдинова Айсылу Мансур кызы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының проект нигезендә идарә итү бүлеге башлыгы |

| | |
|---|---|
| Мансурова Айслу Рәдиф кызы | «Казан дәүләт мәдәният институты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең китапханә-мәгълүмат эшчәнлеге һәм интеллектуаль системалар кафедрасы мөдире (килешү буенча) |
| Мартынов Евгений Петрович | «А.С.Пушкин исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасары (эксперт) |
| Натфуллин Дамир Данил улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары |
| Самсонова Виктория Владимировна | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының инфраструктура белән тәэмин ителеш һәм иҗади индустрияләр бүлеге башлыгы |
| Таҗетдинова Руфинә Ринат кызы | «Казан театр училище (техникум)» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры |
| Тарханова Алсу Габдрахман кызы | алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Татарстан – новый век» – «Татарстан – яңа гасыр» республика иҗтимагый берләшмәсенең Югары советы башкарма комитеты рәисе (килешү буенча) |
| Фәйзуллина Диана Фәрид кызы | «Казан дәүләт мәдәният институты» югары белем бирү федераль дәүләт мәгариф учреждениесенең музеология, культурология һәм сәнгать белеме кафедрасы мөдире (килешү буенча) |
| Хәсәнова Гүзәл Наил кызы | «Юлбасма» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы (килешү буенча) |
| Якупов Илфир Илшат улы | «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе директоры (эксперт). |